ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

26.12.2020

№ 1302

«Белем бирү оешмалары студентларына һәм Алабуга муниципаль районы яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзаларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә һәм Алабуга муниципаль районы иҗтимагый тормышында актив катнашучы студентларга, яшьләр иҗтимагый берләшмәләре лидерларына һәм активистларына адреслы ярдәм күрсәтү максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Белем бирү оешмалары студентларына һәм Алабуга муниципаль районы яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзаларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү турында» 2019 елның 11 декабрендәге 1831 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Белем бирү оешмалары студентларына һәм Алабуга муниципаль районы яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзаларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен бирү турындагы Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
3. Белем бирү оешмалары студентларына һәм Алабуга муниципаль районы яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзаларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен бирү турында комиссия төзергә (2 нче кушымта).
4. Белем бирү оешмалары студентларына һәм Алабуга муниципаль районы яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзаларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен бирү буенча комиссия турындагы Нигезләмәне расларга (3 нче кушымта).
5. Алабуга муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендияләрен финанслауны Алабуга муниципаль районы «Барс» Яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең агымдагы финанславы исәбенә карауны тәкъдим итәргә.

6. Алабуга муниципаль районы «Барс» Яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директорына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип, күләм һәм социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы билгеләгән форматлар нигезендә, әлеге карарга таянып социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.
7. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Р. Яһудинага йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 1302 ” 26 . 12.2020 ел

карарына 1 нче кушымта

**Белем бирү оешмалары студентларына һәм Алабуга муниципаль районы яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзаларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен бирү турында Нигезләмә**

1. Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясе (алга таба - стипендия) Алабуга муниципаль районының яшьләр иҗтимагый берләшмәләре составына керә торган һәм районның иҗтимагый тормышында актив катнашучы студентларына һәм гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларына адреслы ярдәм күрсәтү максатыннан гамәлгә ашырыла.

2. Алабуга муниципаль районының белем бирү оешмалары студентларына һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзаларына стипендия билгеләү Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен бирү комиссиясе карары нигезендә Алабуга муниципаль районының «Барс «Яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тәкъдиме буенча елга бер тапкыр гамәлгә ашырыла.

Стипендия түләү Алабуга муниципаль районының «Барс «Яшьләр үзәге» МБУ финанславы хисабына бирелә.

3. Стипендияләрне раслауга кандидатлар исемлеге Алабуга муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү мәгариф оешмалары, яшьләр иҗтимагый берләшмәләре тәкъдиме буенча төзелә.

4. Кандидатлар исемлеге стипендиатлар раслана торган Комиссиягә фикер алышу өчен тапшырыла Кандидатлар бер календарь елга раслана.

Комиссиянең стипендия алуга кандидатларны раслау турындагы беркетмәсе нигезендә яшьләр сәясәте өлкәсендә район Башлыгы стипендиясен бирү турындагы диплом белән бүләкләнәләр.

5. Стипендия билгеләү өчен түбәндәге номинация гамәлгә куела:

| Номинация | Таләпләр алу өчен стипендияләр | Стипендияләр саны | Стипендия күләме *елына мең сум.* |
|---|---|---|---|
| Ел җәмәгатьчесе | - шәһәр һәм республика яшьләр чараларында катнашу;<br>- шәһәр яшьләр чараларын һәм акцияләрен оештыру;<br>- районда яшьләр хәрәкәтен үстерүгә шәхси өлеш; | 3 | 12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - актив җәмәгать эшчәнлеге;<br>- яхшы өлгереш. | | |

6. Стипендия алуга кандидатлар арасында һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү оешмалары студентлары һәм Алабуга муниципаль районының яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзалары катнаша, алар рәсми төстә эшкә урнашмаган булырга тиеш.

7. Агымдагы елның 20 декабреннән дә соңга калмыйча, стипендия алуга кандидатлар күрсәтү өчен Алабуга муниципаль районының «Барс «Яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

- кушымта нигезендә үтенеч;
- халыкара, бөтенроссия, республика, район конкурслары дипломнарының күчермәләре;
- нәтиҗәле ярышлар турындагы беркетмәдән өземтә;
- уку елына өлгереш табеле (студентлар өчен номинация);
- уку урыныннан, иҗтимагый берләшмәдән дәгъвачының характеристикасы (тасвирламасы);
- паспорт күчермәсе;
- РФ территориясендә яшәү урыны буенча салым органында физик затны исәпкә кую турында таныклык күчермәсен (ИНН);
- мәҗбүри пенсия иминләштерүенең иминият таныклыгы күчермәсе.

Дәгъвачы турында белешмәләрне белем бирү оешмасы яки иҗтимагый берләшмә җитәкчесе әзерли һәм имзалый.

8. Һәр кандидатура буенча фикер алышу үткәрелә, кергән документлар карала һәм карар кабул ителә. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм Алабуга муниципаль районының «Барс» яшьләр үзәге» МБУ өч ел дәвамында саклана.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 1302 ” 26.12.2020 ел

карарына 2 нче кушымта

**Белем бирү оешмалары студентларына һәм Алабуга муниципаль районының яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзаларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен бирү буенча комиссия составы**

**Комиссия рәисе:**

| | |
|---|---|
| Л.Ф. Нургаянов | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |

**Рәис урынбасары:**

| | |
|---|---|
| Л.Р. Яһудина | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Н.П. Шалаумова | - Алабуга муниципаль районы Хокук палатасы рәисе (килешү буенча); |
| Э.И. Садыйкова | - Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча); |
| М.И. Сафин | - «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МКУ башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы; |

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 1302 ” 26.12.2020ел

карарына 3 нче кушымта

**Белем бирү оешмалары студентларына һәм Алабуга муниципаль районы яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзаларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен бирү комиссиясе турында**

**Нигезләмә**

1. Белем бирү оешмалары студентларына һәм Алабуга муниципаль районы иҗтимагый берләшмәләре әгъзаларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен бирү комиссиясе (алга таба Комиссия) Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары - Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендияләрен Алабуга муниципаль районы студентларына һәм Алабуга муниципаль районы иҗтимагый берләшмәләре әгъзаларына бирү буенча кандидатларның документларын һәм кергән материалларны карау.

4. Комиссия Комиссия рәисе, аның урынбасары, Комиссия секретаре һәм әгъзалары составында төзелә. Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне аның рәисе башкара.

5. Комиссия утырышлары агымдагы елның дүртенче кварталында үткәрелә. Комиссия утырышын Комиссия рәисе яисә, ул булмаган очракта, комиссия рәисе урынбасары алып бара.

6. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия әгъзалары үз хокукларын өченче затларга, шулай ук Комиссия әгъзалары булган затларга тапшырырга хокуклы түгел. Комиссия карарлары комиссиянең утырышта катнашучыларның ачык тавыш бирү юлы һәм күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Комиссия рәисе тарафыннан раслана.